ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.02.2023 с. Майдан 12

«Урман участогы башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль белем бирү учреждениесен бетерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышы үткәрү турында

Россия Федерациясе Граждан кодексы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Югары Ослан муниципаль районы Мәйдан авыл җирлеге Уставы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. “Урман участогы башлангыч гомуми белем бирү мәктәбе” муниципаль мәгариф учреждениесен бетерү мәсьәләсе буенча гражданнар җыелышын Югары Ослан районы, Тәмте урманчылыгы бистәсе, Урман урамы адресы буенча үткәрергә.

2. Гражданнар җыелышын 2023 елның 7 мартында 9 00 сәгатьә Югары Ослан районы, Тәмте урманчылыгы бистәсе, Урман урамы адресы буенча мәдәният йортында уздырырга.

3. Әлеге карарны Мәйдан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы В.В.Михеев